МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.07.2021 г.Казань № 484

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 2 августында 7834 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 16 июлендәге 560 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белеш-мәләр тапшырырга тиешле Татарстан

Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2018 елның 16 июлендәге 560 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 20 октябрендәге 739 номерлы бое-рыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти хо-лыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Респуб-ликасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9. социаль ярдәм чаралары методологиясе бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант, әйдәп баручы белгеч;»;

3.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.13. мәшгульлекнең актив сәясәт чараларын гамәлгә ашыру бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;»;

3.14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.14. хезмәт базарын анализлау һәм фаразлау, дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә мониторинг бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;»;

3.18 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

3.24[1] пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.24[1]. тормыш эшчәнлеге чикләнгән затларны социаль интеграцияләү бүлегендә – әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;».

Министр вазыйфаларын башкаручы Р.Ф. Вәлиуллов